


Котлау сайты

*Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин*

# БӘХЕТ ҺӘМ СӘГАДӘТ ДОГАСЫ

**Казан шәһәре**

**2013 ел**

بسم اللّٰه الرحمن الرحيم

# Кереш сүз

Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләребез булсын, Мөхәммәд (с.г.в.)нең рухына салаватларыбыз ирешсен.

Хөрмәтле дустым! Пәйгамбәребез (с.г.в.): “***Дога кылу – гыйбадәтнең җелеге (нигезе)***”, – дип әйткән. Аллаһы Тәгаләне танымыйча һәм дога кылмыйча яшәгән бәндә бик тирән гафләт йокысында гомер кичерә. Дога чишмәсеннән авыз итмәгән кеше үзен һәм башкаларны “мин бәхетле” дип ялганламасын.

“Бәхет һәм сәгадәт догасы”н күңелен биреп, ихлас йөрәктән бөтен шартларын җиренә җиткереп укыган кеше инде кырык көннән соң яхшы якка үзгәрешләр күрә башлар. Әмма ул кәрамәтләрне беркемгә дә сөйләмичә сер итеп саклау кирәк. Шушы очракта гына аның бәрәкәте югалмас, иншааллаһ.

## “Бәхет һәм сәгадәт догасы”ның тарихы

Борынгы китапларда язылганча, элеккеге заманда Бәхетле Халид исемле бер патша була. Патшалыгында яшәгән бөтен кешеләр аны бик хөрмәт итә торган булалар. Үзеннән олыраклар аны үз баласы кебек, яшьтәшләре бер туганы я якын дусты кебек, ә үзеннән кечеләр үз әтиләре кебек сөя торган булалар. Аның Мәрҗән исемле чибәр, акыллы хатыны, ике кызы һәм яраткан бердәнбер улы була. Бөтенесе аны сөеп хөрмәт иткәнгә күрә, булган берничә дошманы аңа каршы сүз дә әйтә алмый торган була. Патшаның байлыгы, какшамас сәламәтлеге, кешеләр алдында булган дәрәҗәсе, дошманнарының да аның каршында тетрәп торулары бөтенесен хәйран калдыра иде. Халид патшаның авызыннан чыккан һәм һәрдаим кешеләрнең колакларында яңгыраган сүзе “Аллаһка бөтен нигъмәтләре өчен рәхмәтем булсын, бөтенесе бәхетле булсын” дигән сүз була. Шуның өчен аны Бәхетле Халид,

ягъни һәркемгә бәхет очкынын таратучы патша дип әйтә торган булалар. Үләргә берничә көн кала ул улы Мансурны чакыра да: “Сөекле улым! Мин берничә көннән соң бәхет чыганагы булган Аллаһы Тәгалә янына китәчәкмен, сезнең арада соңгы көннәремне яшим. Шуңа күрә сиңа бер олы хәзинә калдырам”, – ди һәм гомере буе муенына асып йөргән бөти капчыгыннан кечкенә генә бер китап алып, улы Мансурның кулына бирә. “Улым, бел: дөньяда һәм, иншааллаһ, ахирәттә дә бәхетле булуымның сәбәбе һәм сере шушы “Бәхет һәм сәгадәт догасы”на нигезләнгән”, – ди. Улы Мансур доганы кулына алып күкрәгенә кыса һәм күз яшьләрен түгә-түгә әтисен кочаклап: “Әтием, син беркайчан да үзеңнең яшьлегең турында һәм бигрәк тә бу серле дога турында бернәрсә дә сөйләгәнең булмады”, – дип эндәшә. “Әй сөекле улым! Мин фәкыйрьлектә һәм ятимлектә үстем. Миңа алты яшь булганда, яраткан әнием вафат булды. Гаиләдә җиде бала булып, әтиебез тәрбиясенә калдык. Ачлы-туклы үскәндә, әтиемнең боерыгы белән ун яшемдә көтүчелек хезмәтен башлап җибәрдем. Болыннар, урманнар һәм елгалар янында үтте минем яшьлегем. Һәрбер акыллы кеше бәхет эзләгән кебек, мин дә бәхет эзләдем. Буш вакытымны китап укуда, күкләргә карап, тирән фикер йөртүдә үткәрә идем. Минем иң яраткан эшем – дин кешеләре белән очрашып, аларның фикер йөртүләрен тыңлап тору иде. Юлыма очраган галим һәм дөнья күргән аксакалларга: “Кешенең бәхете нәрсәдә икән”, – дип сорау бирә идем. Шулай итеп егерме өч яшемне тутыргач, әтием белән Исфахан шәһәренә бардык. Ул шәһәрдә яшәгән әтинең дусты шейх Нуретдин янына кунакка кердек. Әлеге изге кеше янына барып кергәч үк, ул мине гомеремдә беренче тапкыр күргән кеше буларак йөземә карады һәм: “Бәхет

эзләүче Халид бүген максатына ирешер”, – дип, елмаеп, минем маңгаемнан үпте. Һәм минем этиемә эндәшеп: “Бу егет минем янда калачак”, – диде. Әтиемнең мине калдырырга теләге булмаса да, башын иде һәм бу изге кешенең тәкъдимен кире какмады. Әйе, чыннан да, шейх Нуретдин бик гаҗәп кеше булып чыкты, үзенең сөйгән кызы Мәрҗәнне миңа никахлаштырды, шулай итеп мин аның кияве дә булып куйдым. Аның тәкъдиме белән Исфахан шәһәрендә патшаның тән сакчысы булып хезмәт итә башладым. Көндезләрен хезмәттә, кичләрен бераз ял иткәннән соң шейх Нуретдиннең боерыгы белән “Бәхет һәм сәгадәт догасы”н укый идем. Бу доганы укый башлагач ук гаҗәп хәлләр пәйда булды. Кырыгынчы төнендә Адәм атабызны (с.г.в.) төшемдә күрдем, ул миңа: “Әй углым, “Бәхет һәм сәгадәт догасы”н укыр алдыннан йөз тапкыр “Әй Аллаһым! Гөнаһларыбызны гафу ит”, дип, үзең һәм бөтен кешеләрнең гөнаһлары гафу ителүен сора”, – дип әйтте. Ни гаҗәп, төшне күргән төннең иртәсендә шейх Нуретдин миңа: “Нигә Адәм (с.г.в.) атабыздан үзең өчен дога кылдырмадың”, дип әйткәч, төшемне белүеннән хәйран калдым, чөнки мин төшне беркемгә дә сөйләмәгән идем. Йөзенче көнне төшемдә Ибраһим (с.г.в) пәйгамбәрне күрдем. Ул миңа: “Әй углым, “Бәхет һәм сәгадәт догасы”н укыр алдыннан эчкерсез изгелек эшлә һәм йөз тапкыр: “Аллаһка рәхмәтем булсын, бөтен кешелек дөньясына бәхет булып кайтсын”, дип әйт”, – дип нәсыйхәтен бирде. Өч йөз унөченче көнне Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрне күрдем. Ул миңа: “Әй Халид! Синең икенче исемең бәхетле булыр, әмма моның бер шарты бар: доганы укыр алдыннан өч йөз унөч тапкыр, мин бөтен кешелек дөньясына бәхет телим, дип әйт”, – дип боерды. Бу

доганы бөтен шартларын үтәп укый башлавыма бер ел булгач, изге Хозыр (с.г.в.)не төшемдә күрдем. Ул мине кочаклап алды һәм елмаеп: “Бу дога синең йөрәгеңне үзгәртте. Шушы мизгелдән алып синең йөрәгең бөтен нәрсәне яхшы якка үзгәртә алачак, хәсрәт синең колыңа әйләнде, син исә бәхетнең солтаны булдың. Халид, син тиздән Исфаханның данлыклы вәзире, аннан соң патшасы булачаксың. Әмма бер нәрсәне онытма: тәкәбберләнсәң һәм йөрәгеңә хөсетлек утын кертсәң, сиңа насыйп булган бөтен нәрсәдән мәхрүм булачаксың. Аллаһы Тәгалә сиңа озын гомер насыйп итәчәк, ике кыз һәм бер угыл бүләк итәчәк. Үләр алдыннан “Бәхет һәм сәгадәт догасы”н улыңа васыять итеп калдыр, ул да синең кебек укысын һәм бу доганы бөтен кешеләргә таратсын. Бу доганы шартларын китереп укыган кешенең өстендә рәнҗешләр булмаса, Аллаһы Тәгалә аңа ике дөнья сөенечен бирер, авырулары булса, сихәтләндерер, сихер, шайтан һәм пәриләр аңа кагыла алмас. Дөньяга килеп киткән бөтен изгеләр һәм ике дөнья бәхетенә ирешкән кешеләр бу доганы телләренә, йөрәкләренә һәм тормышларына сеңдерделәр һәм санап бетерә алмаслык дәрәҗәдә уңышларга ирештеләр”, – дип, миңа бу доганың серләрен һәм хикмәтләрен ачты”. Әнә шулай дип сүзен тәмамлады олы яшен тутырган Халид патша.

Шулай итеп, беренче тапкыр бу доганы аның улы Мансур кулдан язып, кешеләргә тарата башлады. Бу доганы укыган һәм укып, аны башкаларга өйрәткән, китап рәвешендә тараткан, башка кешеләрнең дә бу доганы укуларына сәбәпче булган кешегә үлгәннән соң да бу эшенең бәрәкәте килеп торыр, иншааллаһ.

***Бу доганы укыр алдыннан үтәлә торган шартлар:***

1. Госелле һәм тәһарәтле булу.
2. Беркемгә дә ачу тотмау һәм кемне булса да ачуландырган булса, аннан гафу сорау. Һәм доганы укыр алдыннан, ким дигәндә, 100 тапкыр: ***“Әй Аллаһым! гөнаһларыбызны гафу ит”***, дип әйтү.
3. Йөрәкне тәкәбберлек һәм хөсетлек хисләреннән, фикерләреннән пакълау.
4. Тиешсез берәр әйбер алган булсак, аны киредән үз иясенә кайтару.
5. Доганы укыр алдыннан берәр яхшылык эшләү. (Мәсәлән, күршене булса да чакырып, чәй эчерү). Ул изгелекне эчкерсез эшләгәннән соң: “***Аллаһка рәхмәтем булсын, бөтен кешелек дөньясына бәхет булып кайтсын***”, дип, ким дигәндә, 100 тапкыр әйтү.

## Бәхет һәм сәгәдәт догасы

أعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ * بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ
اللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَي آلِ مُحَمَّدٍ * اللَّهُمَّ إِنِّي أَسْئَلُكَ بِحَقِّ الْعَرْشِ وَ عَظَمَتِهِ وَ الْكُرْسِيِّ وَ سَعَتِهِ * وَ اللَّوْحِ وَ حُرْمَتِهِ * وَ الْقَلَمِ وَ حِفْظِهِ * وَ الْمِيزَانِ وَ خِفَّتِهِ وَ الصِّرَاطِ وَ رِقَّتِهِ * وَ جَبْرَائِيلَ وَ اِمَامَتِهِ * وَ اِسْرَافِيلَ وَ نَفْخَتِهِ * وَ مِيكَائِيلَ وَ رِسَالَتِهِ * وَ عَزْرَائِيلَ وَ حَوْلَتِهِ * وَ رِضْوَانَ وَ جَنَّتِهِ * وَ مَالِكٍ وَ زَبَانِيَتِهِ * وَ آدَمَ وَ صَفْوَتِهِ * وَشِيثَ وَ هَيْبَتِهِ * وَ اِدْرِيسَ وَ رَفْعَتِهِ * وَ نُوحٍ وَ سَفِينَتِهِ * وَ اِبْرَاهِيمَ وَ خُلَّتِهِ * وَ اِسْمَاعِيلَ وَ ذَبِيحَتِهِ * وَ اِسْحَاقَ وَ حُرْمَتِهِ * وَ يَعْقُوبَ وَ حَسْرَتِهِ * وَ يُوسُفَ وَ عِزَّتِهِ * وَ شُعَيْبَ وَ ابْنَتِهِ * وَ مُوسَي وَ كَلِمَتِهِ * وَ هَارُونَ وَ خَشْيَتِهِ * وَ صَالِحٍ وَ نَاقَتِهِ * وَ هُودٍ وَ ذُرِّيَّتِهِ * وَ دَاوُودَ وَ صَفْوَتِهِ * وَ سُلَيْمَانَ وَ مَمْلَكَتِهِ * وَ دَانِيَالَ وَ حِكْمَتِهِ * وَ يُونُسَ وَ دَعْوَتِهِ * وَ أَيُّوبَ وَ بَلْوَتِهِ * وَ زَكَرِيَّا وَ عَفْوَتِهِ * وَ يَحْيَي وَ عِبَادَتِهِ * وَ عِيسَي وَ رِفْعَتِهِ * وَ خَضِرَ وَ سِيَاحَتِهِ * وَ مُحَمَّدٍ الْمُصْطَفَي صَلَّي اللَّهُ عَلَيْهِ وَ

سَلَّمَ وَ شَفَاعَتِهِ * وَ الْقُرْآنِ الْعَظِيمِ وَ تِلَاوَتِهِ * وَ الْعِلْمِ وَ دِرَاسَتِهِ * لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ الْمَلِكُ الْحَقُّ الْمُبِينُ * لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ الْمَلِكُ الْحَقُّ الْيَقِينُ * رَبُّنَا وَ رَبُّ آبَائِنَا الْأَوَّلِينَ لَآ إِلَهَ إِلَّا أَنْتَ سُبْحَانَكَ إِنِّي كُنْتُ مِنَ الظَّالِمِينَ * لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ لَهُ الْمُلْكُ وَ لَهُ الْحَمْدُ يُحْيِي وَ يُمِيتُ وَ هُوَ حَيٌّ لَا يَمُوتُ بِيَدِهِ الْخَيْرُ وَ هُوَ عَلَي كُلِّ شَيْئٍ قَدِيرٌ * لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ وَ لَهُ الْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ * لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ إِقْرَارًا بِرُبُوبِيَّتِهِ سُبْحَانَ اللَّهِ لِعَظَمَتِهِ * وَ أَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ * وَ أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ يَا نُورَ السَّمَاوَاتِ وَ الْأَرْضِ يَاذَ الْجَلَالِ وَ الْإِكْرَامِ* يَا حَيُّ يَا قَيُّومُ * أَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَي مُحَمَّدٍ عَبْدِكَ وَ عَلَي آلِ مُحَمَّدٍ كَمَا صَلَّيْتَ وَ سَلَّمْتَ وَ بَارَكْتَ وَ رَحِمْتَ وَ تَرَحَّمْتَ عَلَي إِبْرَاهِيمَ وَ عَلَي آلِ إِبْرَاهِيمَ فِي الْعَالَمِينَ * رَبَّنَا إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ * اللَّهُمَّ إِنَّكَ تَعْلَمُ سِرِّي وَ عَلَانِيَتِي فَاقْبَلْ مَعْذِرَتِي وَ تَعْلَمُ حَاجَتِي فَاعْطِنِي سُؤَالِي وَ تَعْلَمُ مَا فِي نَفْسِي فَاغْفِرْلِي ذُنُوبِي فَإِنَّهُ لَا يَغْفِرُ الذُّنُوبَ إِلَّا أَنْتَ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ * أَللَّهُمَّ إِنِّي أَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي هُوَ مَكْتُوبٌ عَلَي أَجْنِحَةِ جَبْرَائِيلَ وَ مِيكَائِيلَ وَ إِسْرَافِيلَ وَ عَزْرَائِيلَ عَلَيْهِمُ السَّلَامُ * يَا رَبِّ وَ أَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي هُوَ مَكْتُوبٌ عَلَي أَجْنِحَةِ حَمَلَةِ الْعَرْشِ وَ الْكُرْسِيِّ وَ الْمَلَائِكَةِ الْمُقَرَّبِينَ الَّذِي يَدْعُونَ بِهِ إِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ أَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي هُوَ مَكْتُوبٌ فِي التَّوْرَاةِ وَ الْإِنْجِيلِ وَ الزَّبُورِ وَ الْفُرْقَانِ إِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ أَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي بِهِ رَحْمَتُكَ وَ سَتْرُكَ عَلَي الْعَالَمِينَ إِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ أَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي كَلِمَاتِكَ التَّامَّةِ الطَّيِّبَاتِ إِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ أَسْئَلُكَ بِحَقِّ وَجْهِكَ الْكَرِيمِ إِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ أَسْئَلُكَ بِحَقِّ الْأَسْرَارِ الَّتِي فِي قُلُوبِ الصَّادِقِينَ إِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ أَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي سَبَّحَ بِهِ الدِّينُ إِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ أَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي نَعَتْ بِهِ آدَمَ فَثَبَتَ بِهِ عَلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ أَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي قَرَأَ شِيثُ النَّبِيُّ عَلَيْهِ السَّلَامُ إِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ أَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي قَرَأَ إِدْرِيسُ عَلَيْهِ السَّلَامُ إِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ أَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي قَرَأَ نُوحٌ عَلَيْهِ السَّلَامُ وَ نَجِّي بِهِ مِنَ الطُّفَانِ إِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ أَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي قَرَأَ إِبْرَاهِيمُ عَلَيْهِ السَّلَامُ إِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ

اَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي قَرَأَ اِسْمَعِيلُ عَلَيْهِ السَّلَامُ فَنَجِي بِهِ مِنَ الذَّبْحِ اِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ اَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي قَرَأَ اِسْحَاقُ عَلَيْهِ السَّلَامُ اِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ اَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي قَرَأَ يَعْقُوبَ عَلَيْهِ السَّلَامُ اِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ اَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي تُعِزُّ بِهِ مَنْ تَشَآءُ وَ تُزِلُّ بِهِ مَنْ تَشَآءُ * يَا رَبِّ وَ اَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي تَسْمَعُ الْاَرْضُونَ وَ تَشَقَّقُ مِنْ هَيْبَتِهِ اِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ اَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي يَصْعَدُ بِهِ جِبْرَائِيلُ عَلَيْهِ السَّلَامُ اِلَي السَّمَاءِ وَ يَنْزِلُ اِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ اَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي دَعَاكَ بِهِ آدَمُ عَلَيْهِ السَّلَامُ أَجِبْتَهُ * يَا رَبِّ وَ اَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي دَعَاكَ بِهِ دَاوُودُ عَلَيْهِ السَّلَامُ فَالْحَدِيدُ كَانَ فِي يَدِهِ كَالشَّمْعِ اِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ اَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي قَرَأَ بِهِ سُلَيْمَانُ عَلَيْهِ السَّلَامُ اِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ اَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي دَعَاكَ بِهِ أَيُوبُ عَلَيْهِ السَّلَامُ فَنَجِي بِهِ عَنْ عَذَابِ الدُّودِ اِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ اَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي قَرَأَ مُوسَي عَلَيْهِ السَّلَامُ عَلَي جَبَلِ طُورِ بِكَلِمَتِهِ وَ كَلَامِكَ الْعَظِيمِ اِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ اَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي قَرَأَ يُوسُفُ عَلَيْهِ السَّلَامُ وَ دَعَاكَ بِهِ وَ رَأَي يَعْقُوبَ وَ تَوَابِعَهُ بِبَرَكَتِهِ اِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ اَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي قَرَأَ عِيسَي عَلَيْهِ السَّلَامُ وَ دَعَاكَ بِهِ فَاحْيَيْتَ بِهِ الْمَوْتَي وَ أَبْرَأْتَ بِهِ الْاَكْمَهُ وَ الْاَبْرَصَ اِلَيْكَ * يَا رَبِّ وَ اَسْئَلُكَ بِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِي قَرَأَهُ يُوسُفُ عَلَيْهِ السَّلَامُ وَ دَعَاكَ بِهِ فَاَخْرَجْتَهُ مِنَ الْبِئْرِ وَ سِجْنِ الْمِصْرِ الْقَاهِرَةِ وَ اللَّهُ غَالِبٌ عَلَي أَمْرِهِ وَ لَكِنَّ اَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَعْلَمُونَ * اللّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَي آلِ مُحَمَّدٍ

**Аллааһүммә салли гәләә Мүхәммәди үә гәләә әәли Мүхәммәд. Аллааһүммә инниии әсьәлүкә бихәккыйль гәрши үә гәзамәтиһии үәл күрсиййи үә сәгәтиһии үәл ләүхи үә хүрмәтиһии үәл каләми үә хифзыйһии үәл мийзәәни үә хыйффәтиһии үәс сыйраатый үә риккатиһии үә җәбрааилә үә имәәмәтиһии үә исраафиилә үә нәфхатиһии үә миикәәәиилә үә рисәәләтиһии үә гәзрааааиилә үә хәүләтиһии үә ридъүәәнә үә җәниәтиһии үә мәәликин үә зәбәнийәтиһии үә әәдәмә үә сафьүәтиһии үә шиисә үә һәйбәтиһии үә идриисә үә рафьгәтиһии үә нүүхи үә сәфиинәтиһии үә ибраа-һиимә үә хулләтиһии үә исмәәгиилә үә зәбиихәтиһии үә исхәәка үә хүрмәтиһии үә йәгькуубә үә хәсратиһии үә йүүсүфә үә гиззәтиһии үә шүгәйбә үә ибнәтиһии үә мүүсәә үә кәлимәтиһии үә һәәрууиә үә хашьйәтиһии үә саалихин үә нәәкатиһии үә һүүди үә зүрриййәтиһии үә дәәүүдә үә сафьүәтиһии үә сүләймәәнә үә мәмләкәтиһии үә дәәнийәәлә үә хикмәтиһии үә йүүнүсә үә дәгьүәтиһии үә әййүүбә үә бүлүүәтиһии үә зәкәриййәә үә гәфьүәтиһии үә йәхьйәә үә гибәәдәтиһии үә гиисәә үә рафьгәтиһии үә хадыйра үә сәйәәхәтиһии үә мүхәммәдинил мүсътафәә салләллааһу гәләйһи үә сәлләмә үә шәфәәгәтиһии үәл куръәәнәл гәзыймә үә**

тиләәүәтиһии үәл гильмә үә дираасәтиһии ләәә иләәһә илләллааһуль мәликүл хәккуль мүбиин ләәә иләәһә илләллааһуль мәликүл хәккуль йәкыйн. Раббүнәә үә раббү әәбәәәинәл әүүәлиин ләәә иләәһә илләәә әңтә сүбхәәнәкә иннии күңтү минәз заалимиин. Ләәә иләәһә илләллааһу үәхдәһүү ләә шәриикә ләһ ләһүл мүлкү үә ләһүл хәмдү йүхьйии үә йүмиитү үә һүә хәййү лләә йәмүүтү бийәдиһиль хайру үә һүә гәләә күлли шәй-иң кадиир. Ләәә иләәһә илләллааһу үәхдәһүү ләә шәриикә ләһү үә ләһүл хәмдү лилләәһи раббил гәәләмиин. Ләәә иләәһә илләллааһу икъраарам бирубубиййәтиһии сүбхәәнәллааһи лигәзамәтиһии. Үә әшһәдү әлләәә иләәһә илләллааһу үәхдәһүү ләә шәриикә ләһүү үә әшһәдү әннә мүхәммәдән гәбдүһүү үә расүүлүһү йәә нүүра ссәмәәүәәти үәл әрдый йәә зәл җәләәли үәл икраам йәә хәййү йәә каййүүм. Аллааһүммә салли гәләә Мүхәммәдин гәбдикә үә гәләәә әәли мүхәммәдиң кәмәә салләйтә үә сәлләмтә үә бәәракьтә үә рахимтә үә тәраххәмтә гәләәә ибраaһиимә үә гәләәә әәли ибраaһиимә фил гәәләмиин. Раббәнәә иннәкә хәмиидүм мәҗиид. Аллааһүммә иннәкә тәгьләмү сиррии үә гәләәнийәтии фәкъбәл мәгьзиратии үә тәгьләмү хәәҗәтии фә-әгьтыйнии сүәәлии үә тәгьләмү мәә фии нәфсии фәгъфир лии зүнүүбии фәиннәһүү ләә йәгьфиру ззүн-

үүбә илләәә әңтә бирахмәтикә йәәә әрхәмә рраахимиин. Аллааһүммә инниии әсьәлүкә бихәккый исмикә лләзии һүә мәктүүбүн гәләәә әҗнихәти җәбраааиилә үә миикәәәиилә үә исраафиилә үә гәзраааиилә гәләйһиму ссәләәм. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый исмикә лләзии һүә мәктүүбүн гәләәә әҗнихәти хәмәләтил гәрши үәл күрсиййи үәл мәләәәикәтил мүкаррабиинә лләзиинә йәдгүүнә биһии иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый исмикә лләзии мәктүүбүң фит тәүраати үәл иңҗиили үә ззәбүүри үәл фүркаани иләйкә. Йәә рабби әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии биһии рахмәтүкә үә сәтрукә гәләл гәәләмиинә иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии кәлимәәтикә ттәәәммәти ттаййибәәти иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый үәҗһикәл кәриими иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккыйль әсраари лләтии фии кулүүбис саадикыйнә иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии сәббәхә биһии ддиину иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии нәгәт биһи әәәәдәмә фәсәбәтә биһи гәләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии караә шиисүннәбийу гләйһиссәәләму иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии караә идрису гәләйһиссәләму иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии

караә нуухун гәләйһиссәәләму үә нәҗәә биһи минәттуфәәни иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии караә ибраһииму гәләйһиссәәләму иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии караә исмәгылү гәләйһиссәләәму фәнәҗәә биһи минәззәбхый иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии караә исхәәку гәләйһиссәләәму иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии караә ягкуубу гәләйһиссәләәму иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии түгыззү биһи мәң тәшәәу үә түзиллү биһи мәң тәшәәәәү. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии тәсмәгульәрдуунә үә тәшәккаку мин һәйбәтиһи иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии йәсгәдү биһи җәбраильү гәләйһиссәләәму иләссәмәәи үә йәнзилү иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии дәгәәкә биһи әәәәдәму гәләйһиссәләәму әҗәбтәһү. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии дәгәәкә биһи дәәудү гәләйһиссәләәму фәльхәдииду кәәнә фи йәдиһи кәшшәмги иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии караә биһи сүләймәәнү гәләйһиссәләәму иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии дәгәәкә биһи әейуубу гәләйһиссәләәму фәнәҗәә биһи гән гәзәәбиддүүди иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәк-

**кый смикә лләзии караә муусәә гәләйhиссәләәму гәләә җәбәли туурин бикәлимәәтиhи үә кәләәмикәльгазыыми иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии караә йуусуфу гәләйhиссәләәму үә дәгәәкә биhи үәраә йәгкуубә үә тәүәәбигәhу бибәрәкәтиhи иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии караә гыйсәә гәләйhиссәләәму үә дәгәәкә биhи фә әхйәйтә биhильмәүтәә үә әбръатә биhильәкмәhу үәльәбрасә иләйкә. Йәә рабби үә әсьәлүкә бихәккый смикә лләзии караә йуусуфү гәләйhиссәләәму үә дәгәәкә биhи фә әхраҗтәhу минәльбиэри үәссиҗнильмисриль кааhирати үәллааhу гәәлибун гәләә әмриhи үәләкиннә әксәраннәәси ләәйәгләмуун. Аллааhүммә салли гәләә Мүхәммәди үә гәләә әәли Мүхәммәд.**

## Догадан соң укыла торган теләк

Әй Раббым Аллаh! Укылган hәм язылган бәхет, сәгадәт догасы хөрмәтенә hәркем өчен бәхет, сәгадәт сорыймын. Әй Раббым Аллаh! Булган матур, күркәм исемнәрең хөрмәтенә hәркем өчен бәхет, сәгадәт сорыймын. Әй Раббым Аллаh! Гаршеңнең бөеклеге hәм көрсиеңнең киңлеге хөрмәтенә hәркем өчен бәхет, сәгадәт сорыймын. Әй Раббым Аллаh! Синең хөрмәтеңә лаек булган бөтен барлыкларың хөрмәтенә hәркем өчен бәхет,

сәгадәт сорыймын. Әй Раббым Аллаһ! Изге җирләр Мәккә, Мәдинә һәм анда кылган гыйбадәтләр хөрмәтенә һәркем өчен бәхет, сәгадәт сорыймын. Әй Раббым Аллаһ! Күктә, җирдә булган фәрештәләрең хөрмәтенә, Җәбраил, Микаил, Исрафил һәм Газраил фәрештәләрнең канатларына язылган исемнәрең һәм аларга биргән дан хөрмәтенә һәркем өчен бәхет, сәгадәт сорыймын. Әй Раббым Аллаһ! Җир йөзендә яшәп мәңгелеккә күчкән Пәйгамбәрләрең хөрмәтенә, бигрәк тә сөекле Нух (с.г.в.), Ибраһим (с.г.в.), Муса (с.г.в.) һәм Гайсә (с.г.в.) пәйгамбәрләрең хөрмәтенә һәркем өчен бәхет, сәгадәт сорыймын. Әй Раббым Аллаһ! Җир йөзендә яшәгән изге бәндәләрең хөрмәтенә һәркем өчен бәхет, сәгадәт сорыймын. Әй Раббым Аллаһ! Пәйгамбәрләрнең солтаны, изгеләрнең патшасы булган Мөхәммәд (с.г.в.) хөрмәтенә һәркем өчен бәхет, сәгадәт сорыймын. Әй Раббым Аллаһ! Сөекле колларыңның кабул булган догалары һәм теләкләре хөрмәтенә һәркем өчен бәхет, сәгадәт сорыймын. Әй Раббым Аллаһ! Олы яшен тутырган, чәчләре, сакаллары агарган картлар, ятим балалар һәм тол калган хатыннарның күзләреннән аккан яшьләре хөрмәтенә һәркем өчен бәхет, сәгадәт сорыймын. Әй Раббым Аллаһ! Сиңа гашыйк булган бәндәләреңнең йөрәкләрендә булган мәхәббәтләре хөрмәтенә һәркем өчен бәхет, сәгадәт

сорыймын. Әй Раббым Аллаһ! Изге китаплар Зәбур, Тәүрат, Инҗил, Коръән-Кәрим хөрмәтенә һәркем өчен бәхет, сәгадәт сорыймын. Әй Раббым Аллаһ! Синең ризалыгыңны һәм рәхмәтеңне өмет итеп эшләгән изгелекләр хөрмәтенә һәркем өчен бәхет, сәгадәт сорыймын.

Әй мәрхәмәтле Раббым Аллаһ! Фәрештәләр җиргә иңгән кебек, бәхет тә иңсен җир йөзенә. Көндезләрен кояш яктылыгы белән бөтен җирне биләп алган кебек, бәхет нуры да биләп алсын бөтен дөньяны. Күктән иңгән яңгыр җирне ничек җанландырган булса, бәхет тамчылары да җанландырсын безнең йөрәкләрне. Әй Газиз булган Раббым Аллаһ! Болыннарда үскән чәчәкләр ничек хуш ис тараткан булсалар, бәхет исе дә шулай таралсын бөтен җиһанга. Караңгы төннәрдә тулы ай яктылыгы караңгылыктан ничек коткарган булса, бәхет яктылыгы да коткарсын кешеләрне хәсрәт караңгылыгыннан.

***Укылган бәхет догасы хөрмәтенә бәхет нуры иңсен һәм таралсын бөтен җир йөзенә.***
*(Ахыргы җөмләне җиде тапкыр кабатларга кирәк)*

"Котлау сайты" редакциясе нәшер итте.

https:kotlausaite.ru